ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2023 г. Казань № 383-10/т-2023

«Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар билгеләү турында

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларында, аэропортларында табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләре турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы һәм «Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең 2014 елның 31 октябрендәге 238-т/2 номерлы боерыгы белән расланган Аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә җыемнарны һәм тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу мәсьәләсе буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 24.11.2023 № 50-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә «Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь чик тарифлар һәм җыемнар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь тарифларны (җыемнарны) билгеләү турында» 20.09.2013 № 7-18/т карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2023 № 383-10/т-2023
карарына кушымта

«Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар

| т/с | Җыем һәм тариф исеме | Үлч. бер. | Түләү күләме, тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Очкычны күтәртү-төшерү өчен җыем | сум/т мвм | 929,0 |
| 2. | Авиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җыем | сум/т мвм | 492,0 |
| 3. | Эчке линияләрдә аэровокзал комплексы бирү өчен җыем | сум/пасс. | 145,0 |
| 4. | Эчке һава линияләрендә пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен тариф | сум/пасс. | 373,0 |
| 5. | Һава судноларына авиация ягулыгы салуны тәэмин иткән өчен тариф | сум/т | 2 196,0 |
| 6. | Авиация ягулыгын саклау өчен тариф | сум/т | 1 710,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге